778579920486586875-sas3-0967-c7e-sas-l7-balancer-8080-BAL (мөрәҗәгать итү көне: 10.12.2022).
8.https://yandex.ru/video/preview/?text=«ВДудь»Павел%20Грудинин&path=yandex_search&parent-reqid=1650189007544825-14274482854207427153-vla1-3228-vla-l7-balancer-8080-BAL (мөрәҗәгать итү көне: 10.12.2022).

***И.И. Фазлутдинов***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© И.И. Фазлутдинов

# ИСТОРИЧЕСКИЕ ПРЕДАНИЯ ТАТАРСКОГО НАРОДА В ДОРЕВОЛЮЦИОННОЙ ПЕРИОДИЧЕСКОЙ ПЕЧАТИ

# РЕВОЛЮЦИЯГӘ КАДӘРГЕ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ БИТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТАРИХИ РИВАЯТЬЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Статья посвящена исследованию опубликования татарских исторических преданий на страницах дореволюционной печати, их взаимосвязи с политическими процессами, протекающими в описываемое время. Отдельно выделяются и анализируются научные труды русских ученых. Автор приходит к выводу о том, что произведения данной категории чаще собирались и публиковались в печатных изданиях русскими фольклористами и собирателями народной прозы, в том числе с целью изучения тюркских народов, населяющих Россию, и описания их быта, обычаев и верований.*
***Ключевые слова:*** *татарский фольклор, исторические предания, дореволюционная печать, исторический аспект, журнал.*
***Abstract.*** *The article is devoted to the study of the publication of Tatar historical traditions on the pages of the pre-revolutionary press, their relationship with the political processes taking place at the time described. The scientific works of Russian scientists are singled out and analyzed separately. The author comes to the conclusion that the works of this category were more often collected and published in printed publications by Russian folklorists and collectors of folk prose, including for the purpose of studying the Turkic peoples*

*inhabiting Russia and describing their way of life, customs and beliefs.*

***Keywords:*** *tatar folklore, historical traditions, pre-revolutionary press, historical aspect, magazine.*

Буыннан-буынга тапшырылган риваятьләрдә һәм легендаларда халыкның тарихы, аның көнкүреше, әхлагы, гореф-гадәтләре яктыртыла, дөньяга карашлары чагыла. Фольклорның әлеге үзенчәлекле өлкәсе галимнәрнең, сәяхәтчеләрнең игътибарын һәрвакыт җәлеп итте. Мәсәлән, В.Н. Татищев үзенең «Россия тарихы» дип исемләнгән хезмәтендә, татарларның тарихы һәм этнографиясе мәсьәләләренә кагылып, халыкның телдән сөйләнеп йөри торган риваятьләренә таяна [1, с. 66], [2, с. 402]. Риваятьләргә һәм легендаларга XVIII гасырның тагын бер танылган галиме П.И. Рычков та игътибарсыз калмый. Ул үзенең «Ырынбур губернасы топографиясе»ндә топонимик атамаларның килеп чыгышын аңлатучы халык хикәяләренә мөрәҗәгать итә. Бу текстларның бер өлеше тарихи характердагы мәгълүматларны да чагылдыра [3]. Шул ук вакытта П.И. Рычков үзе анализлаган татар фольклоры материалларын жанр ягыннан да аерып барырга омтыла: риваять, әкият, хикәя, ышану, уйдырма һ.б. XVIII гасырның икенче яртысында Урал якларына сәяхәт иткән галимнәрнең (П.С. Паллас, И.И. Лепехин) юл язмаларында шулай ук татар этногенетик легендалары һәм риваятьләре китерелә [4], [5, с.36-64.]. Галимнәр тарафыннан бу төр риваятьләр борынгы тарихи-генеалогик дип билгеләнә (Ф.А. Нәдершина).

XIX гасырның беренче яртысында шагыйрь-декабрист П.М.Кудряшовның, танылган лексикограф В.И.Дальның һәм башка рус әдәбиятчыларының татар көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, ышануларын тасвирлауга багышланган этнографик очерклары һәм мәкаләләре вакытлы матбугатта дөнья күрә.

Уфадагы туган як тарихын өйрәнүче Б.С.Юматов мәкаләсендә Башкортстанда яшәүче Ногай морзалары Аксак-Килембәт һәм Каракилембәт арасындагы ызгышлар, башкортларның сансыз бәла-казалары һәм аларның патша Явыз Иванга мөрәҗәгать итүләре турындагы тарихи риваятьләр искә алына [6, с.45-48], [7, с.297-298]. Бу хезмәтләрдә кулланылган фольклор материалы аның фрагментарлыгына, информантлар турындагы, кайда һәм кайчан теркәлүенә бәйле мәгълүматлар

булмауга карамастан, ул чордагы татар һәм башкортлар арасында киң таралган «чын тарихи» риваятьләр турында билгеле бер мәгълүмат бирә.

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы рус галимнәреннән М.В. Лоссиевский, Р.Г. Игнатьев һәм Ф.Д.Нефедовның Идел-Урал буенда урнашкан татар һә башкортларның риваятьләрен җыю, өйрәнү һәм киң җәмгыятькә таныту эшендә зур хезмәт куюын аерып күрсәтергә мөмкин. Алар, Салават Юлаев турындагы очерк һәм мәкаләләрендә, тарихи документлар һәм «Пугачев фольклоры» әсәрләреннән кала, барыннан да элек риваятьләргә һәм легендаларга таяналар [8, с.83-100], [9, с.221], [10].

Санкт-Петербург шәһәрендәге «Наблюдатель» журналында чыккан мәкаләсендә С.Г. Рыбаков XIX гасыр татар, башкорт, мари халыкларының үзенчәлекле – җыр белән хикяләү аралашып барган – «катнаш» формада яшәп килүче җыр-риваятьләре турында бай күзаллау тудыра [11, с.274]; [12, с.294-309]. Тикшеренү барышында шунысы күзгә ташлана – фольклорчы хәзерге Башкортстан җирендә яшәүче типтәрләрне татарлардан аермалы буларак башка этник төркем буларак күрсәтә.

А.Г.Бессонов XIX гасыр азагында, Уфа, Оренбург губерналары буйлап сәяхәт итеп, татар һәм башкорт халыкларының бәян итүгә нигезләнгән фольклорына караган бай материалын туплаган. Галимнең вафатыннан соң дөнья күргән әкиятләр җыентыгында фәнни күзлектән кызыксыну уяткан берничә тарихи эчтәлекле риваять («Башкорт борынгысы», «Янузак-батыр» һ.б.) урнаштырылган [13].

Шулай итеп, татар риваятьләре үрнәкләре революциягә кадәрге чорда ук тарихчылар, сәяхәтчеләр һәм этнографлар тарафыннан язып алынган. Бу жанрны системалы рәвештә җыю һәм фәнни нигездә өйрәнү исә Октябрь революциясеннән соң башланган. Бу Гыйльми үзәк, югары һәм махсус уку йортлары, бераз соңрак Казанда фәнни-тикшеренү институты ачылу белән бәйле.

Мәгълүм булганча, «Шура» журналы татар халкының революциягә кадәрге иң популяр периодик басмасы булып тора. Бүгенге көндә классик әдипләр буларак танылган шәхесләр үз вакытында нәкъ шушы журнал битләрендә каләм чарлыйлар.

Мәсәлән, һәвәскәр тарихчы, Казан сәүдәгәре, атаклы нәсел вәкиле М.Аитовның (1823-1890) татар тарихына караган материаллар тупланган күләмле мәҗмугасында татар авылларының килеп чыгышына, Явыз Иван сәясәтенә бәйле этник процессларга, Пугачев восстаниесенә багышланган риваятьләр урын ала. 1886 елның 3 маенда Г. Ильяси Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыятендә М. Аитов риваятьләре турында доклад ясый һәм шул ук елның 13 маенда аларның русчага тәрҗемәсен «Волжский вестник» газетасында бастыра. Риваятьләрнең татарча оригиналы Р. Фәхретдинов тарафыннан 1913 елда «Шура» журналында басылып чыга. Әмма Р. Фәхретдинов басмасы тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калып килде. М. Аитовның Пугачев турындагы һәм башка риваятьләре К. Насыйриның 1926 елда чыккан «Басылмаган әсәрләр» китабына кертелгән. Алар озак еллар буе К. Насыйриның үз әсәрләре буларак тәкъдим ителеп киләләр [14].

Журналист Сабирҗан Кормашинең бу өлкәдәге тырышлыклары да игътибарга лаек [15], [16], [17].

Башка риваятьләр турыдан-туры басылмаса да, редакция тарафыннан халык белән әңгәмә, ягъни сорау-җавап формасында яктыртыла. Асылда, бу сорулар Ислам диненә бәйле булганга, алар «Дин һәм дин галимнәре» рубрикасында чыга. Әлеге рубликада ислам изгеләре, дини эчтәлекле легендаларга игътибар бирелә.

Безнең тикшеренүебез өчен тагын бер әһәмиятле чыганак – Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенең рәсми органы – Уфа шәһәрендә чыккан «Мәгълүмате Мәхкәмәи шәргыя Оренбургия», ягъни «Мәгълүмат» журналы. Монда төрле елларда күп кенә кызыклы материаллар урын ала. Нигездә, алар дини темага багышланган яки аның белән бәйле булалар. Мәсәлән, «Чишмә мәкъбәрәсе вә болгарлар хакында», «Хуҗалар тагы хакында» (тагы – тавы, дигән сүз), «Вамбери сүзенә бинаән Аксак Тимернең холкы вә табигате», «Тимерләң» (русчадан тәрҗемә) һ.б.

Шуны да әйтмичә үтеп булмый, безнең күзәтүләр буенча революциягә кадәрге газета-журналларда Тамерлан исеме нәкъ Тимерләң дип йөргән. Моның сәбәбе, безнең фикеребезчә, Тимур исеменә чыгышы белән иран кушымчасы «lang»ны өстәүгә бәйле.

Нәтиҗәдә, Тимур-Лянг, ягъни Аксак Тимер, кимсетүле кушаматы барлыкка килгән һәм Тимерлан буларак Европада танылып, кулланылышка кереп киткән, шулай ук үз исеме белән беррәттән тарихта да теркәлгән [18, с.210-213].

Тикшерелгән мәкаләләрдән күп кенә зур тарихи вакыйгаларның кайтавазы булган аерым сюжетларның күпчелек төрки халыклар өчен уртак булуы күренә. Аларда Болгар чоры – изге чор, илнең мөстәкыйль һәм көчле вакыты буларак тасвирлана. Шул ук вакытта дини мотивларга нигезләнгән, Ислам изгеләренә багышланган һәм дидактик характердагы риваятьләр дә еш кына очрый [19], [20].

Рус һәм чит ил тарихчылары, этнографлары, сәяхәтчеләр, миссионерлар татарлар яшәгән төрле территорияләрдә сәфәр иткән вакытларда, сәяхәтләрен чагылдырган язмаларында халык иҗатына да таяналар, игътибар итәләр, һәм бу материаллар, аларда тасвирланган халык хәтере вакытлы матбугатта да чагылыш таба.

Төп нәтиҗәләрнең беренчесе буларак тарихи риваятьләрнең революциягә кадәрге татар телендәге вакытлы матбугатта чагыштырмача сирәк очраганлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Шул ук вакытта, киресенчә, рус галимнәренең татар халык иҗатына карата игътибарын билгеләп үтәргә мөмкин – «Археология, тарих һәм этнография хәбәрләре»ндә әкияти характерда булмаган татар фолкьлорына һәм шул исәптән тарихи риваятьләренә караган язмалар (рус телендә) зур өлешне тәшкил итә. Бу уңайдан атаклы тюрколог, Казан университеты профессоры Н.Ф Катанов эшчәнлеген аерым билгеләү урынлы була.

1894нче елда ул Император Фәннәр академиясе язмларының XXV томына кушымта буларак мөселман легендаларана багышланган һәм аларның рус теленә тәрҗемәләрен үз эченә алган аерым җыентык бастыра [21]. Шул ук елдан башлап Н.Ф. Катанов Себер ханлыклары тарихына, шул исәптән Күчем һәм Ермакка багышланган риваятьләрне Тубыл губерния музееның еллык басмаларында да тәкъдим итә. Автор материалларга үз искәрмәләрен дә бирә [22]. Галим татар риваятьләренең аерым мотивларын, образларын, сюжетын өйрәнә, әлеге тикшеренүләрне яктырткан материалларның күбесе вакытлы матбугатта чагылыш таба, аерым өлеше тулысы белән бастырыла [23]. Галим XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар

фольклорын өйрәнүгә багышланган дистәләгән фәнни-популяр хезмәт иҗат итә, аларның безнең тикшеренүгә караган өлеше әдәбият исемлегендә төгәл күрсәтелә, мәсәлән: атна көннәренең һәм кояш елы айларының, халыкта яшәгән сынамышларның мәгънәләрен аңлатучы риваять һәм легендалар.

Югарыда язылганнардан чыгып, түбәндәгеләрне ассызыклау кирәк:

Революциягә кадәрге вакытлы матбугатта тарихи риваятьләр бик еш күренмәсә дә, алар системалы рәвештә басылып бара һәм төрле күләмдә барлык газета-журналларда да күренә дияргә мөмкин.

Тематик яктан, күбесе Ислам диненә багышланган булса да, шул ук вакытта гомумдәүләт, сәяси, көнкүреш мәсьәләләрне дә чагылдыралар, халыкның сынамышларын һәм ышануларын аңлаталар, үткәненә мөнәсәбәтен күрсәтәләр.

Кулланылган чыганаклардан ачык күренгәнчә, бу чорда җыеп алынган риваятьләрне өйрәнү һәм халыкка таныту эшендә рус этнографлары күпкә активрак була, моның сәбәбен без Россиядәге төрки халыкларны өйрәнү һәм аларның яшәешләрен тасвирлау, Россиядәге рольләрен күрсәтү омтылышында күрәбез.

Халыкның иҗтимагый-сәяси тарихындагы әлеге катламның шактый аз өйрәнелгән булуы, тикшеренүчеләр алдында яңа бурычлар куя. Галимнәр тарафыннан тиешле дәрәҗәдә анализланмаган һәм фәнни яктан яктыртылмаган әлеге төр материаллар аерым гуманитар фәннәргә үз өлешләрен кертә ала.

**Литература:**

1. Татищев В.Н. История Российская / В.Н. Татищев. – М.;Л. – 1964. – Т. IV. – С. 66.
2. Татищев В.Н. История Российская / В.Н. Татищев. – М.;Л. – 1968. – Т. VII. – С. 402.
3. Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии / П.И. Рычков. – Оренбург. – 1887. – Т.1.
4. Паллас П.С. Путешествие по разным провинциям Российского государства / П.С. Паллас. – СПб. – 1786. – 614 с. – Перевод с немецкого. В 3-х частях. Ч. 2, кн. 1.
5. Лепехин И.И. Полное собрание ученых путешествий по России, издаваемое императорской Академией наук в 5 томах / И.И. Лепехин. – СПб. – 1822. – Т. 4. – С. 36-64.

6. Юматов В.С. Древние предания башкирцев Чубиминской волости / В.С. Юматов // Оренбургские губернские ведомости. – 1848. – № 7. – С. 45-48.

7. Юматов В.С. О названиях башкирцев / В.С. Юматов // Оренбургские губернские ведомости. – 1874. – № 4. – С. 297-298.

8. Нефедов Ф.Д. Движение среди башкир перед Пугачевским бунтом; Салават – башкирский батыр / Ф.Д. Нефедов // Русское богатство. – 1890. – № 10. – С. 83-100.

9. Лоссиевский М.В. Пугачевский бригадир Салават и Фариза / М.В. Лоссиевский // Волжско-Камское слово. – 1882. – С. 221.

10. Игнатьев Р.Г. Башкир Салават Юлаев – пугачевский бригадир, певец-импровизатор / Р.Г. Игнатьев // Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. – Казань. – 1893. – Т. 9.

11. Рыбаков С.Г. Очерк быта и современного состояния инородцев Урала // Наблюдатель. – 1895. – № 7. – с. 274.

12. Рыбаков С.Г. Очерк быта и современного состояния инородцев Урала // Наблюдатель. – 1895. – № 8. – с. 294-309.

13. Башкирские народные сказки / Запись и перевод А.Г. Бессонова. Редакция, введение и примечание проф. Н.К. Дмитриева. Под общ. ред. академика И.Ю. Крачковского. – Уфа: Башгосиздат. – 1941. – 367 с.

14. Алишев С.Х. Каюм Насыри и Мухаметзян Аитов. – Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. – Казань. – 1976.

15. Кормаши Сабирҗан. Изгеләр чишмәсе // Шура. – 1915. – № 9. – Б. 286-287.

16. Кормаши Сабирҗан. Сәхиб әби әүлия булган // Шура. – 1915. – № 12. – Б. 2-3.

17. Кормаши Сабирҗан. Җылау көе // Шура. – 1915. – № 12. – Б. 283.

18. Стеблин-Каменский И.М. Lang «хромой» // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. VIII годичная научная сессия ЛО ИВ АН СССР (автоаннотации и краткие сообщения). – Москва: ГРВЛ. – 1972. – С. 210-213.

19. Һилял сөбуты хакында хәдис вә риваятьләр // Мәгълүмат. – 1908. – №16. – Б. 339.

20. Тәнреколов Г. – Хөтбә хакында риваять (гарәпчә) // Мәгълүмат. – 1908. – № 14. – Б. 298.

21. Катанов Н.Ф. Мусульманские легенды: Тексты и переводы. СПб. – 1894. – С. 2, 44.

22. Катанов Н.Ф. Предание тобольских татар о Кучуме и Ермаке // Ежег. Тоб. губ. музея. – 1894. – Вып. IV. – С. 53-55.

23. Катанов Н.Ф. Татарские сказания о семи спящих отроках // Зап. вост. отд. археол. об-ва. – 1894. – Т. VIII. – С. 223-245.

***Р.А. Фарукшин***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© Р.А. Фарукшин

***Научный руководитель: Р.П.Баканов***
кандидат филологических наук, доцент
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© Р.П.Баканов

## РАЗНООБРАЗИЕ МАНИПУЛЯТИВНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКИХ ТЕЛЕПЕРЕДАЧАХ РОССИИ И США

***Аннотация.*** *В исследовании предпринимается попытка выявить определяющие характеристики телевизионной манипуляции посредством анализа российских и американских информационно-аналитических телепередач. В рассмотренных российских телепередачах наиболее выраженными приёмами оказались «Утвердительные заявления», «Фреймирование» и «Фактор юмора»; в американских аналогах – «Пугающие обобщения», «Повторения», «Фреймирование», «Стереотипизация» и «Прямое обращение к зрителю». В исследовании применены методы контент-анализа, содержательного и сравнительного анализа. Результаты свидетельствуют о сопоставимо высоком уровне эмоциональной манипуляции на ТВ обеих стран.*

***Ключевые слова:*** *манипуляция, СМИ, массмедиа, телевидение, новостные программы, Россия, США.*